**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында» 2004 елның 31 декабрендәге ПУ-824 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 7 декабрендәге ПУ-479 номерлы, 2009 елның 29 гыйнварындагы ПУ-35 номерлы, 2011 елның 7 сентябрендәге ПУ-549 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы, 2014 елның 15 мартындагы ПУ-275 номерлы, 2015 елның 2 мартындагы ПУ-196 номерлы, 2016 елның 11 мартындагы ПУ-236 номерлы, 2018 елның 21 апрелендәге ПУ-329 номерлы, 2019 елның 8 февралендәге ПУ-89 номерлы һәм 2020 елның 6 мартындагы ПУ-158 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Д.Х. Салиховны чыгарырга;

б) Комиссия составына Зәйдуллин Ркаил Рафаил улын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» (Иҗат берлеге) җәмәгать оешмасы рәисен (килешү буенча) кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2021 ел, 15 апрель
№ ПУ-287